ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.02.2021 № 209

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы топонимик комиссиясен төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Алабуга шәһәре» Башкарма комитетын үзгәртеп коруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2020 елның 29 июлендәге карары 491 номерлы карары нмгезендә, Алабуга муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре Башкарма комитеты каршындагы топонимик комиссиясен төзү турында» Алабуга шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 8 июнендәге 15 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы топонимик комиссиясен төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы топонимик комиссиясе турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 209 ” 20.02.2021 ел

карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы**
**Башкарма комитеты каршындагы топонимик комиссиясе составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Нургаянов Ленар Фәрид улы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| 2 | Гыйләҗева Илнара Марат кызы | Алабуга муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 3. | Гыйззәтуллин Илдар Сабирҗан улы | «Алабуга муниципаль районының Җир-мөлкәт палатасы» муниципаль казна учреҗдениесе рәисе (килешү буенча) |
| 4. | Кондратенко Наталья Васильевна | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече |
| 5. | Томилин Андрей Александрович | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы төзелеш Департаменты» муниципаль казна учреҗдениесе директоры (килешү буенча) |
| 6. | Фәретдинов Марсель Баян улы | Алабуга муниципаль районы Советының коррупциягә каршы көрәш тору буенча район башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча) |
| 7. | Шалаумова Надежда Павловна | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 8. | Гыйззәтуллина Кояш Фәнил кызы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| 9. | Разживин Анатолий Ильич | Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга филиалының фәнни эшләр буенча рус теле һәм әдәбияты кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| 10. | Нигамаев Альберт Зөфәр улы | Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга филиалының ватан һәм гомуми тарих кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| 11. | Руденко Гөлзада Рәкыйп кызы | Алабуга дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгының генераль директоры (килешү буенча) |
| 12. | Хөснетдинова Ирина Семеновна | Техник инвентаризация Бюросы башлыгы (килешү буенча) |
| 13. | Баганов Геннадий Петрович | Алабуга муниципаль районы ветераннар Советы рәисе (килешү буенча) |

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы топонимик комиссиясе турында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

Топонимик комиссия (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый эш органы булып тора.

Комиссия башкарма хакимиятнең территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләреннән тора. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Комиссиянең төп бурычлары һәм хокуклары

1. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- шәһәр территориясендә урнашкан урам-юл челтәре элементлары исеменә (атамасына) бердәм якын килүне булдыру, топонимик атамаларны куллануны тәртипкә салу, тарихи атамаларны торгызу һәм аларның исемнәрен үзгәртү, шулай ук аларны саклау буенча җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, вазыйфаи затлар эшчәнлеген координацияләү;

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе раслаган компетенция чикләрендә, шәһәр территориясендә урнашкан урам-юл челтәре элементлары өчен исемнәр (атамалар) ясауда катнашу, алар буенча тәкъдимнәр кертү;

- массакүләм мәгълүмат чараларына шәһәрнең топонимиясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча материаллар әзерләү.

2. Комиссия үзенең төп бурычларын гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

- шәһәр территориясендә урнашкан урам-юл челтәре элементларының исеме (атамасы) буенча кертелә торган тәкъдимнәрнең нигезлелеген топонимик бәяләүне уздыруга, тарихи топонимнарны торгызу яки алмаштыру өчен, аларга карата Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарларының проектларын әзерләүгә;

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каравына топонимик эшне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

- җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук учреждениеләрдән, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле

материаллар соратырга һәм алырга;

- Комиссия утырышларына җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын, топонимика проблемалары буенча тәкъдимнәр керткән авторларны һәм башка кызыксынган хезмәткәрләрне чакырырга;

- аерым эшләрне гамәлгә ашыру өчен, шулай ук консультантлар, галимнәр һәм белгечләрне билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

- топонимиягә кагылышлы мәсьәләләр буенча оператив киңәшмәләр, инструктажлар үткәрергә;

- халык арасында топонимиягә кагылышлы мәсьәләләр буенча сорау алулар үткәрергә;

- Комиссия компетенциясенә керә торган топонимик мәсьәләләр буенча бәхәсләрне карарга һәм алар буенча бәяләмә бирергә;

- топонимия мәсьәләләре буенча башка чараларны гамәлгә ашырырга.

## 3. Комиссия эшчәнлеге тәртибе

1. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма елына кимендә бер тапкыр уздырыла. Утырышның узу вакыты һәм урыны турында комиссия әгъзаларына, утырышта каралырга тиешле документ проектларын тапшырып алдан хәбәр итәләр.

Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзасы, аның карары белән килешмичә, үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушып бирелергә тиеш. Комиссия үз эшчәнлеген комиссиянең елллык эш планы нигезендә гамәлгә ашыра. Планнар комиссия утырышында раслана.

2. Комиссия исемен (атаманы алыштырудан) үзгәртүдән баш тарткан очракта яисә аның карары белән килешмәгән очракта, кире кагылган тәкъдим иткән автор (дәгъвачы) Комиссия карарына законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

3. Комиссия эшчәнлеген мәгълүмати һәм документлар белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.